**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"25" ноябрь 2022 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Түбән Көек торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылы территориясендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Түбән Көек торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, 1 төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Түбән Көек авылы территориясен чистарту, үлән чабу, агач һәм куак кисү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге территориясендә ял итү зонасын һәм җәяүлеләр өчен җәяүлеләр зонасын төзекләндерү;
- Түбән Көек авылының урам юлларын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. 2022 елның Түбән Көек авылы гражданнарының экономияләнгән акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Түбән Көек авылы һәйкәле территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү.

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Түбән Көек авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Көек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.